**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
22.05.2019

КАРАР
ПР-114

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе «Гомуми үсеш бирүче 7нче балалар бакчасы» эшчәнлеген вакытлыча туктатып тору турында**

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе «Гомуми үсеш бирүче 7нче балалар бакчасы»нда капиталь төзекләндерү эшләре алып барылу сәбәпле Башкарма комитет

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 нчы елның 1 июненнән 31 июльгә кадәр муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе «Гомуми үсеш бирүче 7нче балалар бакчасы» эшчәнлеген туктатып торырга.

2. Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе «Гомуми үсеш бирүче 7нче балалар бакчасы»нда тәрбияләнүче балаларның әти-әниләренең язмача ризалыгы нигезендә төркемнәрне түбәндәге балалар бакчаларына йөртеп торырга МБМББУ «Гомуми үсеш бирүче 2нче балалар бакчасы», МБМББУ «Гомуми үсеш бирүче 5нче балалар бакчасы», МБМББУ «Катнаш төрдәге 6нчы балалар бакчасы», МБМББУ «Гомуми үсеш бирүче 4нче балалар бакчасы», МБМББО «Гомуми үсеш бирүче 1нче балалар бакчасы»

3. Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе «Гомуми үсеш бирүче 7нче балалар бакчасы» мөдире Харисова А.М.га

- капиталь төзекләндерү чорында вакытлыча муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе «Гомуми үсеш бирүче 7нче балалар бакчасы»на йөрмәгән балалар өчен түләү алмаска,
- муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе «Гомуми үсеш бирүче 7нче балалар бакчасы» хезмәткәрләренә 2018 нче елның 1 нче сентябрендә үткән тарификация нигезендә хезмәт хакы түләргә.

4. Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе «Гомуми үсеш бирүче 7нче балалар бакчасы»на вакытлыча йөрмәгән балаларның куркынычсызлыгы һәм сәламәтлеге өчен җаваплылыкны ата-аналарга (законлы вәкилләргә) йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http//pravo.tatarstan.ru) һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе И.Ш.Бариев